КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 18 май г.Казань № 708

2025 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2026 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасында энергетиканы үстерү, энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен алга таба тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «2025 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2026 елга бурычлар турында» хисабын хупларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен кертүне тәэмин итәргә.

3. Республика башкарма хакимият органнарына:

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Энергетика ресурсларын куллану турында декларация бирү тәртибен һәм энергетика ресурсларын куллану турында декларация формасын раслау хакында» 2019 елның 28 октябрендәге 707 номерлы боерыгы нигезендә 2025 елга энергетика декларацияләрен, шул исәптән ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре (булганда) буенча бирүне законнар белән билгеләнгән срокларда тәэмин итәргә;

2026 елның 1 июленә кадәр ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре (булганда очракта) өчен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан үзләре кулланa торган дизель һәм башка ягулык, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, ташкүмернең суммар күләмен, шулай ук үзе куллана торган су күләмен киметүнең максатчан дәрәҗәсен чагыштырма шартларда билгеләү буенча методик тәкъдимнамәләрне раслау турында» 2020 елның 15 июлендәге 425 номерлы боерыгы белән нигезендә исәпләп чыгарылган 2027 – 2029 елларга үзләре куллана торган дизель һәм башка ягулык, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, ташкүмернең суммар күләмен, шулай ук үзе куллана торган су күләмен киметүнең максатчан дәрәҗәсен (алга таба – ресурсларны куллануны киметүнең максатчан дәрәҗәсе) билгеләргә һәм җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына кертергә;

2026 елның 1 августына кадәр Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Дәүләт һәм муниципаль берәмлек, эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар катнашында оешмаларның энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программалар формасына һәм аларны гамәлгә ашыру барышы турындагы хисапларга карата таләпләрне раслау хакында» 2014 елның 30 июнендәге 398 номерлы боерыгы нигезендә, ресурсларны куллануны киметүнең билгеләнгән максатчан дәрәҗәсен исәпкә алып, ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең (булганда) энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру программаларын эшләүне һәм элек расланган программаларына төзәтмәләр кертүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен бирүне тәэмин итүне;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Энергетика ресурсларын куллану турында декларация бирү тәртибен һәм энергетика ресурсларын куллану турында декларация формасын раслау хакында» 2019 елның 28 октябрендәге 707 номерлы боерыгы нигезендә 2025 елга энергетика декларацияләрен, шул исәптән ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр (булганда) буенча бирүне законнар белән билгеләнгән срокларда тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасына кертү өчен федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгълүмат бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 25 гыйнварындагы 20 номерлы карары нигезендә законнар белән билгеләнгән срокларда мәгълүмат бирүне тәэмин итүне;

2026 елның 1 июленә кадәр ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр өчен 2027 – 2029 еллар чорына ресурсларны куллануны киметүнең

максатчан дәрәҗәсен билгеләүне һәм җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына кертүне;

2026 елның 1 августына кадәр:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә төбәк һәм муниципаль программаларга карата таләпләрне раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2021 елның 11 февралендәге 161 номерлы карары нигезендә энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча муниципаль программаларны эшләүне һәм элек расланган программаларга төзәтмәләр кертүне тәэмин итүне;

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Дәүләт һәм муниципаль берәмлек, эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар катнашында оешмаларның энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программалар формасына һәм аларны гамәлгә ашыру барышы турындагы хисапларга карата таләпләрне раслау хакында» 2014 елның 30 июнендәге 398 номерлы боерыгы нигезендә, ресурсларны куллануны киметүнең билгеләнгән максатчан дәрәҗәсен исәпкә алып, ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру программаларын эшләүне һәм элек расланган программаларына төзәтмәләр кертүне тәэмин итүне.

5. «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру программаларын эшләгәндә (аларга төзәтмәләр керткәндә), шулай ук энергия сервисы контрактларын төзү юлы белән энергия саклау чараларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә.

6. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә, «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче Бөтенроссия энергия саклау һәм экология фестивалендә Татарстан Республикасының катнашу мөмкинлеген җентекләп эшләргә.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасының «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче Бөтенроссия энергия саклау һәм экология фестивалендә катнашуын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын тормышка ашыру барышы һәм 2025 елга бурычлар турында» 2025 ел, 15 апрель, 230 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры О.В.Коробченкога йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин